**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Детский сад № 21» Чистопольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы мэктэпкэчэ һэм белеем биру муниципаль бюджет учреждениесе «21 нче номерлы балалар бакчасы»**

Рассмотрено и принято в действие на
заседании педагогического совета
протокол № 1 от 25.08.2021

Утверждено и введено в действие
приказом № 91 от 26.08.2021

Заведующий МБДОУ «Детский сад № 21»
_______________Т.Ю. Богданова

# Рабочая программа

## воспитателя по обучению детей татарскому языку муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад № 21» на 2021 -2022 учебный год

г. Чистополь, 2021 г.

**Эчтәлек**


1. Балалар бакчасында татар  балаларына ана теле өйрәтү программасы. Аңлатма язуы......................................... 3
2. I – нче кечкенәләр төркеменә комплекслы – тематик планы татар балаларына ана теле өйрәтү өчен.................. 7
3. II – нче кечкенәләр төркеменә комплекслы – тематик планы татар балаларына ана теле өйрәтү өчен............... 21
4. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. Аңлатма язуы........................................ 34
5. Лингвистик материал сайлау схемасы........................................................................................................... 36
6. “Минем өем” проекты буенча комплекслы - тематик план (Уртанчылар төркеме) ............................................ 40
7. “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча комплекслы - тематик план (Зурлар төркеме) .................................. 50
8. “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча комплекслы – тематик  план (Мәктәпкә әзерлек төркем)................................................................................................................................................. 60
9. Диагностика. Балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләү өчен биремнәр ............................................. 70
10. Кулланылган әдәбият .................................................................................................................... 73

**Балалар бакчасында татар балаларына ана теле өйрәтү программасы.**

**Аңлатма язуы**

«Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләр саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы»нда мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Бу - республикабызда эшләп килә торган милли балалар бакчалары өчен кадрлар әзерләү, аларның белемен күтәрү һәм методик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре. Әлеге проблемаларның бер өлеше “Туган телдә сөйләшәбез” өйрәтү-методик комплектлары ярдәмендә чишелә. Тәкъдим ителгән әсбап – татар балаларын туган телгә өйрәтү, аларның сөйләмен үстерү буенча методик кулланма. Аның төп максаты ана телендә балаларның дөрес һәм яхшы телдән сөйләмен формалаштыру. Кече яшьтән үк баланың сөйләмен үстерү аның аралашу, танып белү, әхлакый һәм рухи юнәлешләр нигезен билгели.

Ул 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү Стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган тел өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максатыннан төзелгән һәм “Туган телдә сөйләшәбез” дип аталган методик әсбап балалар бакчасында беренче кече яшьтәге балалар белән эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. “Туган телдә сөйләшәбез” дип исемләнгән методик комплект икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә хәзерлек төркемнәре өчен дә әзерләнә. Бу комплектның төп максаты балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү булса, төп үзенчәлеге – тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Туган телдә сөйләшергә өйрәтү гаиләдә башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дәвам итә. Ул балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына, мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла. Мәктәпкәчә учреждениеләр, мәгариф системасының беренче баскычы буларак, нәниләрне туган телгә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү “Кроха” программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелә:

I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.
2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).
3. Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

II. Образлы уенчыклар, пластик художестволы образлар аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1. Уенчыклар карау.
2. “Тылсымлы капчык”, “Бу өйдә кем (нәрсә) яши?” дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.
3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.
4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

III. Художестволы картиналары аша (живописный, графический художественный образ) (буяулар һәм буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.
2. “Җанлы” кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Матур әдәбият, юаткычлар, шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр уку.

2. Тәрбияче белән бергә кыска гади әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

V. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуциядән тыш тәрбиячененң сөйләве.

2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр (тәҗрибәдән чыгып, күзәтүләрдән соң).

Методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Нәниләр эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар - “Балалар бакчасы”, “Көз”, “Мин дөньяның бер кешесе”, “Минем әйләнә-тирәм”, “Кыш”, “Яңа ел бәйрәме”, “Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр”, “Халык иҗаты”, “Яз”, “Җәй”. Елга ике тапкыр диагностик методикалар ярдәмендә мониторинг үткәрелә. Мониторинг нәтиҗәләре балаларның персональ карточкаларына языла.

Туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Авторлар эшчәнлек конспектлары язганда үстерелешле өйрәтү, өйрәтү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таяналар. Өйрәтү-тәрбия процессы балаларның “якындагы үсеш зонасында” (Л.С. Выготский) бара. Бу процессны әйдәп баручылар - тәрбиячеләр.

Өченче яшьтәге балалар белән оештырылган эшчәнлек уен характерын ала. Эшчәнлек төрләрендә сөйләм үсешенең *сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* бурычлары хәл ителә.

Балалар белән эшләү процессында *сүзлек эше* зур урын ала. Сүзлек эше- бәйләнешле сөйләм нигезе. Балалар бакчасында сүзлек эшенең өч бурычы чишелә:

1. Иң беренче чиратта, гомуми кулланылыштагы лексика хисабына (предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, алар белән эш-хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.

2. Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.

3. Сүзлекне активлаштыру.

*Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның* төп шарты – тәрбияченең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксик ягын, сүзъясалу ысулларын үзләштерү буенча үткәрелә торган күнегүләр.

*Аваз культурасы тәрбияләү* буенча эш аның сөйләм сулышы, ишетеп кабул итү, артикуляция аппаратын үстерү һ. б. шундый компонентларны үз эченә ала.

*Бәйләнешле сөйләм үстерү* сөйләмнең ике формасын - диалоглы һәм монологлы сөйләм үстерүне күздә тота. Диалоглы сөйләм үстерүдә сорау-җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер-берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологлы сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора.

Балаларны *матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру* – сөйләм үсешенең әһәмиятле бурычы һәм чарасы. Матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру түбәндәге бурычларны чишкәндә тормышка ашырыла:

1. Дөньяны бербөтен итеп кабул итүне, күзаллауларны формалаштыру.

2. Әдәби сөйләмне үстерү.

3.Эстетик зәвыкны, әдәби әсәрне кабул итүне үстерү.

Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү бурычларын чишкәндә өйрәтүнең төрле методлары, алымнары, чаралары кулланыла. Шундый чараларның берсе булып, бармак уеннары тора. Хәрәкәтләнү активлыгы югарырак булган саен, балаларның сөйләме тизрәк һәм яхшырак үсеш ала, сөйләм сыйфаты, төрлелеге белән аерылып тора. Бармак уеннары баш мие эшчәнлегенә, интеллект үсешенә уңай йогынты ясый. Чыннан да, физиологлар, психологлар үткәргән тикшеренүләр (Л.С. Выготский, И.П. Павлов, А.Р. Лурия, А.А. Леонтьев һ.б.) хәрәкәтләнү һәм сөйләм моторикасының үзара бәйле булуын исбатлыйлар.

Балалар белән эшләү дәверендә төрле предметлар тотып биюләр, уеннар киң кулланыла. Нәниләр уенчыкларны яшерәләр, эзлиләр, табалар. Мондый уеннар балаларда зур кызыксыну уята, тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне балалар тырышып кабатлыйлар, “куян булып сикерәләр”, “кошлар булып очалар”, җим чүплиләр”, “аю кебек алпан-тилпән йөриләр”, “әтәч булып кычкыралар” һ.б. Бу уеннарда музыка әсәрләрен куллану балаларның фонематик ишетү сәләтен, ритмикасын, эмоциональ сферасын да баета, үстерә.

Нәниләр белән эшләгәндә “Җанлы картиналар” куллану зур урын алып тора. “Җанлы картиналар” - тышкы кыяфәтләрен көтмәгәндә үзгәртәләр һәм шуның белән балаларның игътибарын җәлеп итәләр. Алар эчтәлеге буенча ике-өч төрле эшчәнлек өчен кулланыла ала. Мондый очракта эшчәнлекнең аерым эпизодларын үзгәртергә кирәк. Мәсәлән, катнашучыларның санын кыскартырга яки арттырырга, яңа элементлар кертергә мөмкин. “Җанлы картиналар”ны темалар буенча сайлау мөһим: урам, йорт һәм кыргый хайваннар, кошлар, кибет һ.б. белән таныштыру.

Балаларның игътибарын туплау, эшчәнлеккә карата кызыксыну уяту, ял иттерү (релаксация) максаты белән шигъри әсәрләргә зур игътибар бирелә. Бу әсәрләрне укыганда балалар эчтәлегенә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар: “яфраклар, кар бөртекләре кебек очалар”, “кер юалар, чайкыйлар, сыгалар”, “кояшны сәламлиләр”, “кояш нурлары ясыйлар” һ.б.

Матур әдәбият, халык иҗаты, күрсәтмәлелек, предметлар белән уен хәрәкәтләре, кошларның, җәнлекләрнең образларын имитацияләү - болар барысы да нәниләрне туган телгә өйрәтүдә, аларның сөйләмен үстерүдә зур әһәмияткә ия. Балалар белән үткәрелә торган эшчәнлек конспектлары тулы, күләмле итеп язылды. Өйрәтү-тәрбия процессында балалар белән эшчәнлекне оештырганда тәрбиячегә иҗади якын килү мөмкинлеге бирелә. Эшчәнлек конспектларын төзегәндә тәрбияче өчен күрсәтмәләр, балаларның якынча җаваплары, балаларны активлаштыру җәя эчендә күрсәтелә. Җәя эчендә күрсәтелгән индивидуаль һәм күмәк кабатлаулар истә калдыру максатыннан аваз, сүз, иҗек, фраза кебек сөйләм элементын кабатлауны күрсәтә. Кабатлауның төрле вариантлары бар: тәрбияче артыннан, балалар артыннан, тәрбияче белән бергә, күмәк, индивидуаль.

Балаларны активлаштыру балаларның җавапларын конкретлаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны, хәрәкәтләрне кабатлату максаты белән эшләнә.

Тәрбияче балаларга гомуми сораулар белән мөрәҗәгать итә, барлык балаларга да бирелгән сорауны кечкенә бала үзенә бирелгән дип кабул итми, шуңа күрә тәрбиячегә соравын конкретлаштырырга кирәк (- Балалар, алма нинди төстә? – Әмир, алма нинди төстә? – Гүзәл, алма нинди төстә? - Балалар, минем янга килегез әле. – Марат, син дә кил әле. –Алсу, син дә кил.).

Без, авторлар коллективы, өйрәтү-методик комплектта тәкъдим ителгән материаллар балаларга туган телне өйрәтүдә һәм аларның сөйләмен үстерүдә тәрбиячеләргә ныклы ярдәмлек булыр дип ышанып калабыз. Әлеге методик әсбап милли балалар бакчасында эшләүче педагогларга, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә, педагогик уку-укыту йортларында белем алучы студентларга адреслана. Алардан киңәшләр, тәкъдимнәр көтеп калабыз.

## Өченче яшьтәге балаларның сөйләм үсеше үзенчәлекләре

Өченче яшьтәге балаларның сөйләм үсешендә мөһим үзгәрешләр бара. Танып белү сферасы камилләшә, сөйләм функцияләре арта. Сөйләм зурлар белән генә түгел, ә балаларның бер-берсе белән аралашу чарасы да булып тора.

Сөйләмне үзләштереп, бала предметларны гына түгел, ә сүзләргә, фразаларга да игътибар итә башлый. Ул зурларның инструкциясен, кушкан, катлаулырак йомышларны да ишетә, кабул итә һәм үти ала. Бу яшьтә сүзлек коммуникатив функциясе белән берлектә гомумиләштерү функциясенең дә камилләшүе дәвам итә. Балаларның сөйләмен формалаштыруда кабул итүнең әһәмияте зур. Бу яшьтә әйләнә-тирә дөньяны сенсор танып белү өстенлекле урын алып тора. Баланың күзаллаулар запасы арта һәм һәр нәрсәне бала сүзләр белән белдерә башлый. Бу үз чиратында сүзлек күләме артуга китерә. 2 яшьтә бала сүзлегендә 270-300 сүз 2,5 яшьтә 400-500 сүз булса, 3 яшьтә 1000-1500 сүзгә җитә. Балалар яңа сүзләрне генә түгел, ә сөйләм әйләнмәләрен дә бик тиз отып алалар һәм кабатлый башлыйлар.

Балалар сөйләмендә бәйлек сүзләр дә очрый, сыйфат һәм рәвешләрнең саны арта. Ел ахырына балалар үз сөйләмнәрендә сыйфат фигыльдән һәм хәл фигыльдән башка барлык сүз төркемнәрен дә кулланалар. Болар барысы да балага үз фикерен формалаштырырга һәм җөмләләрдә белдерергә булышлык итәләр. Балалар кушма җәенке җөмләләрдән дә файдаланалар. Кече яшьтәге балалар нәрсә кирәген, нәрсә

күргәннәрен һәм ишеткәннәрен әйләнә-тирәдәгеләргә ачык итеп аңлата беләләр. Булган тәҗрибәләренә нигезләнеп, өлкәннәр әйткән фразадагы һәр аерым сүзне аңлый һәм хәтерендә калдыра.

Сөйләмнең коммуникатив функциясе камилләшә. Бала диалоглы сөйләмне үзләштерә башлый. Кече мәктәпкәчә яшь чорында диалоглы сөйләм сөйләмдә аралашуның төп формасы булып тора. Үз фикерләрен теләп белдерергә өйрәнә. Өченче яшь ахырына балалар күп сораулар белән мөрәҗәгать итәләр, бу аларның сөйләм һәм фикерләү үсеше турында әйтә. Ике яшьтән соң баланың яшьтәшләре белән аралашу теләге арта. Фонетик яктан караганда әле баланың сөйләме камил түгел. Өч яшькә туган телнең барлык авазларын кабул итсә дә, аларны бик дөрес итеп әйтә алмыйлар.

Өченче яшьтәге бала аның белән аралашканда зурларның нәрсә турында сөйләвен яхшы аңлыйлар. Алар белән үткән һәм киләчәк турында да сөйләшергә була. Сөйләмнең актив булмаган формасы барлыкка килә. Балалар әдәби әсәрләрне, әкиятләрне, зурлар сөйләгәнне тыңлыйлар һәм аңлыйлар.

Кабул иткән нәрсәләрен бала үз теләге белән сөйләмдә чагылдырырга омтыла (сөйли, эчтәлеген сөйли). Тасвирый сөйләм һәм монологлы сөйләм формалаша. Болар барысы да баланың күзаллаулары киңәюе, аның мөстәкыйльлеге һәм хыял итүе үсеше белән бәйле. Бу яшь чоры сүз иҗаты үсеше өчен башлангыч булып тора. Ул баланың хисләрен, кичерешләрен ачык чагылдыра.

Баланың сөйләмендә үзенең төрле хисләрен, кичерешләрен ачык итеп чагылдыра белүе нигезендә ел ахырына сөйләм тагын сәнгатьлерәк була башлый. Болар барысы да аның шәхес үсешенә зур йогынты ясый. Сүзлек эше, сөйләмнең грамматик ягы, аваз культурасы, бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру өстендә эшләү кебек бурычларны максатчан чишкәндә генә баланың сөйләм үсешендә уңышларга ирешергә мөмкин.

Беренче кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерылып тора. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру барышында алып барыла. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгендә торды. Балаларның сөйләмен үстерү эше “Кроха” программасында күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелде:

1. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1). Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.

2). Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).

3). Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, олылар хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

2. Образлы уенчыклар, пластик художество образлары аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1). Уенчыклар карау.

2). “Тылсымлы капчык”, “Бу өйдә кем (нәрсә) яши? дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.

3). Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.

4). Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

3. Художество картиналары аша (буяу һәм буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1). Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стена картиналарын карау, “җанлы” кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

4. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

5. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

# I – нче кечкенәләр төркеменә комплекслы – тематик планы

# татар балаларына ана теле өйрәтү өчен

# Сентябрь

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **I – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | **1.Безнең бакча**<br><br>“Чишенү бүлмәсен карау” (Танып белү) | 1. Балаларны чишенү бүлмәсе, аның билгеләнеше, андагы җиһазлар белән таныштырырга, группадагы бүлмәләрдә ориентирлашу тәҗрибәсе тупларга.<br>2. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерергә.<br>3. Җиһазларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| **I – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Кем нәрсә эшли? (Сөйләм үстерү) | 1. Балаларның, аралашу чарасы буларак, сөйләмен үстерергә ярдәм итәргә, картинкалар карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтергә.<br>2. Игътибарын, кабул итүләрен үстерергә.<br>3. Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| **I – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | “Үчтеки, үчтеки” такмагын уку (Әдәбият уку) | 1.Фольклор әсәрләренә кызыксыну уятырга; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә.<br>2. Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>3. Нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Йомшаккай бездә кунакта. (Танып белү) | 1. Балаларның группадагы уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгы формалаштырырга, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлек запасын киңәйтергә.<br>2. Тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләге үстерергә.<br>3. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Предметларның төсләрен тану һәм атау. “Паровоз” дидактик күнегүе. (Сөйләм үстерү) | 1. Төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баетырга (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтүдә күнектерергә.<br>2. Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерергә.<br>3.Эшчәнлеккә карата кызыксыну, бер-берең белән шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Ә.Бикчәнтәеваның “Туп туп-тубыбыз” шигырен уку (Әдәбият уку) | 1. Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, таныш предметларны таный һәм атый белергә өйрәтергә, шигырьне укыганда, шигырьнең аерым сүзләрен әйтергә мөмкинлек бирергә, тупның төсләрен ныгытырга.<br>2. Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>3. Уңай эмоциональ атмосфера тудырырга, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Йомшаккай тагын бездә кунакта. (Танып белү) | 1. Балаларны уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтергә; уенчыкларның өлешләре исемнәрен, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертергә.<br>2. Тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>3. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, көлкеле уенчыклар белән уйнаудан канәгатьләнү, шатлану хисләре тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Уенчыклар бездә кунакта. (Сөйләм үстерү) | 1. Төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баетырга (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт), аралашу осталыгын формалаштырырга.<br>2. Тәрбиячене күрсәтмәсе буенча исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор сәләтләрен, игътибарын, хәтерен үстерергә.<br>3. Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләргә. |

| | | |
|---|---|---|
| **III– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | С.Сөләймmanagedованың “Ике” шигырен уку<br>(Әдәбият уку) | 1. Балаларда шигъри әсәргә кызыксыну уятырга, поэтик әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, баланың үзе турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итәргә, “кул”, “аяк”, “колак”, “күз”, сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>2. Һәр әгъзаның яшәү өчен әһәмияткә ия булуын һәм кирәклеген тоемлауларын үстерергә.<br>3. Культура-гигиеник күнекмәләр тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Е.Батуринаның “Тупны коткарабыз” картинасын карау<br>(Танып белү) | 1. Картинаның эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтергә.<br>2. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерергә.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Юыну бүлмәсен карау.<br>(Танып белү) | 1. Балаларның юыну бүлмәсендәге предметларның (сабын, сөлге, кран, су, теш щеткасы, теш пастасы) функциональ билгеләнеше турындагы күзаллауларын ачыкларга.<br>2. Сүзләрне (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.)төрле грамматик формаларда куллану осталыгын, сөйләм активлыгын, инициативасын үстерергә.<br>3. Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Пирамидалар. | 1. Балаларны предметларның сыйфат билгеләрен - зурлыгын, төсен билгеләргә һәм атарга өйрәтергә. Төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр), зурлыкны (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштырырга. Аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерергә.<br>2. Игътибарны, кабул итүне, сенсор сәләтләрне үстерергә.<br>3. Түземлелек, дидактик уеннарга кызыксыну тәрбияләргә. |

## Октябрь

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **I – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | 2.Көз.<br>Көзге табигать<br>(Танып белү) | 1. Баларның көз (табигаттәге үзгәрешләр,кешеләрнең киеме һ.б) турындагы күзаллауларын формалаштыру.<br>2. Баларның күзәтүчәнлеген, игтибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерү.<br>3. Көзге табигаткә соклану хисләре тәрбияләү. |
| **I – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Яшелчәләр.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге, помидор, суган, кишер, аларның үзлекләре) хисабына балаларның сүзлеген баетырга, тәрбияче кисәтүе буенча яшелчәләрне тану осталыгына өйрәтергә, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерергә.<br>2. Балаларның сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>3. Яшелчәләргә карата уңай караш, тыңлаучанлык тәрбияләргә. |
| **I – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Йорт хайваннарын чакыру эндәшләрен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Эндәшнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, фольклорның бу төр жанрына кызыксыну уятырга, текстның эчтәлеге буенча аваз ияртемнәрен, ымлыклар әйтүдә күнектерергә, тәрбиячене сорауларына аңлап җавап бирүләрен ныгытырга.<br>2. Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Хайваннарны ярату теләге тәрбияләргә. |
| **II – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Җиләк-җимешләр.<br>(Танып белү) | 1. Тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләрне аерырга өйрәтү, җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтү, сүз байлыгын үстерү.<br>2. Баларның игтибарын, үзләштерү, кабул итү һәм тою сәләтен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү.<br>3. Балаларны сөйләм этикетының гади формаларын( исәнләшү, саубуллашу) куллана белергә гадәтләндерү. |

| | | |
|---|---|---|
| **II – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Җил исә” уен күнегүе.<br>“Кем нәрсә ашый?” дидактик күнегүе. | 1. Балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгытырга. Җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыкларга, ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый дигән фигыльләрне сөйләмдә активлаштырырга. Авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтергә.<br>2. Сөйләм сулышын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерергә.<br>3. Җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **II – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Д.Гарифуллинның ”Йә, алар кемнәр икән?” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итәргә, “бак-бак”, “Мә-мә”, “Кар-кар” аваз ияртемнәрен кабатларга.<br>2. Балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итәргә; сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга.<br>3. Кошларга, хайваннарга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Яшелчәләр: помидор, кыяр, кишер белән таныштыру.<br>(Танып белү) | 1. Баларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгыту; форма, төс, тәм үзенчәлекләре( кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл,хуш исле, каты...) белән таныштыру.<br>2. Балаларның сенсор тою сәләтен, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерү.<br>3. Баларны сөйләм этикетының гади формаларын (исәнләшү, саубуллашу) кулланырга гадәтләнедерү, зурлар хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү. |
| **III– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Урманда.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларның олылар белән аралашу теләген хупларга, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтергә: йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре. Кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштырырга: төлке бара, куян сикерә, аю алпан - тилпән йөри һ.б.<br>2. Ишетү игътибарын, координацияләрне, ритм хисен үстерергә. |
| **III– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Б.Рәхмәтнең “Су” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтергә, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, [ю] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә, шигырьнең эчтәлегенә эмоциональ җавап бирүләренә булышлык итәргә.<br>2. Сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга.<br>3. Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләүне дәвам итәргә. |
| **IV – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Рәсемдәге кошларны карау.<br>(Танып белү) | 1. Балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдырырга; аларның кызыклы гадәтләрен күрергә өйрәтергә.<br>2. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сүзлек запасын үстерергә.<br>3. Кошларга карата йомшак караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Безнең Алсу” сериясеннән рәсем карау.<br>(Танып белү) | 1. Картинадагы предметларны аера һәм атый, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә белергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләрен үстерергә.<br>3. Картинаны кызыксынып карау теләге тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Көз (йомгаклау чарасы) | 1. Балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен kияләр) ныгытырга.<br>2. Тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтергә. Төсләрне ныгытырга.<br>3. Балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итүне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерергә. Балаларда рәсем ясауга кызыксыну уятырга.<br>Көзге табигать белән соклану хисләре, пөхтәлек тәрбияләргә. |

# Ноябрь

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **I– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Мин дөньяның бер кешесе<br><br>Минем исемем бар.<br>(Танып белү) | 1.Баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтү, исемнәрне истә калдырырга, оялчанлыкны җиңәргә ярдәм итү;<br>2.Тәрбияче әйткәнне ишетергә һәм аңларга, кайбер фразаларны (Минем исемем – Алсу) кабатларга күнектерү, хәтерне игтибарны үстерү;<br>3.Балаларда зурларга һәм яштәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **I– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Алсу бүлмәсе.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларны җиһазны таный һәм атый белергә өйрәтергә, өстәл, урындык, караватка, шкаф, көзге кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштырырга, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерергә (Өстәл артыннан чык, өстәл астыннан чык).<br>2. Балаларның эмоциональ сфераларын, кызыксынуларын үстерергә.<br>3. Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| **I– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Шигъри әсәрне аңларга өйрәтергә; балаларга дөньянын бер кешесе дигән күзаллауны бирергә. Кәҗәне танырга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>2. Кәҗә, чирәм, сакал сүзләре хисабына сүзлек запасын киңәйтергә, хәрәкәтләрне үстерергә.<br>3. Бер-беренә карата һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Бу мин.<br>(Танып белү) | 1. Организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштырырга, балага үзенербөтен итеп кабул итәргә өйрәтергә, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыкларга һәм ныгытырга.<br>2. Гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәчләр, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>3. Үзеңне, үзеңнең гәүдә өлешләрен ярату һәм сакчыл караш тәрбияләргә, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудырырга. |
| **II– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Бу өйдә кем яши?” дидактик уены.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Группага йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итәргә, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтергә (Бергә яшәрбез, Кем яши? Ишек шакый? һ.б.). Сорау сүзләрен куллана белүдә күнектерергә.<br>2. Игътибарны, кабул итүләрен, диалогик сөйләмне үстерергә. |
| **II– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | З.Туфайлованың “Ул зу-у-у-ур үскән” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Шигъри әсәрне кабул итәргә һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтергә, утырткан, сипкән, үскән кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүзлекне киңәйтергә, активлаштырырга; шигырьне истә калдыруларына булышлык итәргә; сүз төркемнәрен дөрес кулланып диологлы сөйләмне баетырга.<br>2. Уңай эмоциональ халәтне үстерергә.<br>3. Гөлләргә карата сакчыл караш, гөлнең матурлыгына соклана белүләрен тәрбияләү. |
| **III – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | **Минем әйләнә-тирәм.**<br>Алсу бездә кунакта.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларны шәһәрдә яшәүче кешеләрнең һөнәрләре (табиб, полиция хезмәткәре) белән таныштырырга, грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>2. Игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итүне үстерергә.<br>3. Һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| **III – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Яраткан уен бүлмәбез.<br>(Танып белү) | 1. Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерергә, уен (группа) бүлмәсе һәм алдагы почмаклар белән таныштырырга, һәр әйбернең үз урыны дигән күзаллауны балаларның аңына җиткерергә.<br>2. Сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләрен үстерергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>3. Җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләү. |
| **III – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | М.Җәлилнең “Маэмай” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Шигъри әсәр белән таныштырырга, аңлап кабул итәргә өйрәтергә, бармак театры элементларын куллануны дәвам итәргә.<br>2. Сүзлек запасын киңәйтергә (маэмай, борын, йөгерә, өрә, ишетә, күрә). |

| | | |
|---|---|---|
| **IV – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “КамАЗ” машинасы.<br>(Танып белү) | 1. Балаларны “КамАЗ” машинасын һәм аның өлешләрен таный, атый белергә өйрәтергә, уенның сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясау осталыгы булдырырга.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональ сферасын үстерү.<br>3. Балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә кызыксыну уяту. |
| **IV – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Әминәнең туган көненә килегез.<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. [К] авазын сүзләрдә һәм сөйләмдә әйтә белүләрен ныгытырга, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтергә. Савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга, гомумиләштерүче сүзләрне (савыт–саба) аңлый һәм куллана белүләрен формалаштыруны, җөмләләр белән җавап бирүдә күнектерүне дәвам итәргә.<br>2. Инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерергә. Башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудырырга (“Кунакка кил”).<br>3. Үзара аралашуга омтылыш тәрбияләү. |
| **IV – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | М. Җәлилнең<br>“ Әтәч”<br>шигырен уку. | 1. Күрсәтмәлек кулланмыйча әдәби әсәрне тыңлый һәм кабул итү күнекмәләрен формалаштырырга, кычкырганда барлыкка килгән тавышлары буенча йорт кошларын таный һәм атый белергә өйрәтергә, [к] авазының әйтелешен ныгытырга.<br>2. Шигырьне бармаклар театры ярдәмендә сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерергә.<br>3. Йорт кошларына карата мәхәббәт тәрбияләргә. |

## Декабрь

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **I– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Минем урамым” “җанлы картинка”сын карау (Танып белү) | 1. Балаларны урам һәм аның объектлары белән таныштырырга. аларга карата кызыксыну тудырырга.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүзлеген үстерергә.<br>3. Урамга соклану хисе тәрбияләү. |
| **I– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Песи-нечкәбил” бишек җырын уку.<br>(Матур әдәбият) | 1. Шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлап кабул итүләренә ирешү, бишек җыры текстына туры китереп хәрәкәтләр өйрәтү.<br>2. Балаларның игътибарын үстерү.<br>3. Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү. |
| **I– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Минем гаиләм.<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. Сүзләрдән ягымлы сүзләр (әти-әтием, әни-әнием, әби-әбием, сеңел-сеңлем) ясарга өйрәтергә, [Ә] авазының әйтелешен ныгытырга, аның ачык тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүдә, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>2. Игътибарны, хәтерне, зурлар һәм балалар белән ирекле аралашуларын (йомыш кушканда-конверт эчендә нәрсә бар-кара әле; картинкадагы кешеләрнең халәтен күрсәтергә) үстерергә.<br>3. Гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләргә. |
| **II – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Ж.Тәрҗемановның “Маэмай” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият). | 1. Шигъри әсәрне аңларга өйрәтүне дәвам итәргә, аерым сүзләрне (Акбаем, маэмаем, өрә) һәм зур булмаган фразаларны (“ташлар ыргытмагыз!”, “Мине котыртмагыз!”) кабатларга өндәргә.<br>2. Балаларның игътибарын үстерергә.<br>3. Эткә карата миһербанлылык тәрбияләргә. |
| **II – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | **Яңа ел бәйрәме.**<br>Купшы чыршы.<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. Сузык һәм тартык авазларны, аваз иялтемнәрен ачык әйтүдә, сыйфатларны дөрес куллана белүдә күнектерергә. “Төбендә” сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтергә.<br>2. Сорауларга җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>3. Табигатьобъектларына (чыршыга) соклану хисләре тәрбияләргә. |

| | | |
|---|---|---|
| **II – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Электр лампасы белән таныштыру.<br><br>(Танып белү) | 1. Электр турында балаларга элементар төшенчә (электр тогы электр чыбыкларында яши; утны яндыру өчен өзгечкә (выключатель) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток йөри башлый) бирергә. Электр, ток, чыбык, өзгеч (выключатель) сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен үстерергә. Ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерергә.<br>3. Сакчыллык тәрбияләргә. |
| **III – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Ә.Бикчәнтәеваның “Беренче адым” шигырен уку.<br><br>(Матур әдәбият). | 1. Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; кайбер сүзләрне әйтергә өндәргә; бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтергә.<br>2. Игътибарын үстерергә.<br>3. Күмәк эшчәнлек күнекмәләре тәрбияләргә. |
| **III – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Гирлянда.<br>(Танып белү). | 1. Балаларга гирлянда турында элементар белемнәр бирергә, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгытырга, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белүдә күнектерергә.<br>2. Балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, сүзлеген һәм шатлану хисләрен үстерергә.<br>3. Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| **III – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Куян<br>чыршы янында. | 1. Сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, “кайда?, “кая?” сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итәргә. Тавыш көчен дөрес куллану белү осталыгын формалаштырырга.<br>2. Игътибарны, тәрбиячenең сүзле күрсәтмәләре буенча эшләү осталыгын үстерергә.<br>3. Нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Карга әйтә...” эндәшеı уку. | 1. Шигъри әсәрне кабул итәргә өйрәтергә, кошлар турында балаларның белемнәрен ныгытырга һәм киңәйтергә; аларның тышкы кыяфәтенә игътибар итәргә, сүзлекне баетырга; [к] авазының дөрес әйтелешен булдырырга.<br>2. Балаларның игътибарын үстерергә. |
| **IV – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Яшел чыршы.<br>. | 1. Балаларны чыршыны карарга өйрәтергә, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларына төгәллек кертергә һәм баетырга.<br>2. Балаларның “Яңа ел бәйрәме” темасы буенча сүзлекләрен активлаштырырга, тәрбияче соравына җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>3. Матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Песи белән кәҗә чыршы янында.<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларны тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итәргә. Сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар куллануны активлаштырырга. [Ж] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә һәм җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләрен формалаштырырга, аваз иялтемнәрен кабатлаганда тавыш көчен җайлый белүдә күнектерергә.<br>2. Игътибарны, кабул итүне, тәрбиячeнең сүзле күрсәтмәләрен үтәү осталыгы үстерергә. |

## Гыйнвар

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **II– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Ап-ак кар ява.<br>(Танып белү) | 1. Балаларны кар һәм аның сыйфаты (ап-ак, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштырырга, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>2. Балаларның сүзлек запасын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>3. Кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләргә. |

| | | |
|---|---|---|
| **II– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Кошлар.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларны аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (гөр – гөрли, чырык-чыркылдый, кар-каркылдый) ясарга өйрәтергә. Гомумиләштерә торган сүзләрне (тавык, әтәч, каз –йорт кошлары) куллануда күнектерегә. Кошлар исеме, гәүдә өлешләре, хәрәкәтләр атамасы хисабына сүзлекләрен активлаштырырга. Балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итәргә.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмнең аваз культурасын үстерергә.<br>3. Кошларга карата кызыксыну, алар турында кайгырту теләге тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Алсуны урамга киендерәбез.<br>(Танып белү) | 1. Балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертергә; прогулкага киендерү эзлеклелеген һәм киемнәрнең билгеләнешен истә калдырырга өйрәтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>2. Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүзлек запасын үстерергә.<br>3. Башкаларга ярдәм итү теләге, киемнәргә сак караш тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Юлны чистартабыз.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларның кыш турында, кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштырырга. Көрәк белән эшләү күнекмәсенә өйрәтергә. Урам себерүче хезмәте белән таныштырырга. Урам себерүче, көрәк, кар көрәргә, атарга кебек сүзтезмәләр һәм сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга. Аерым сүзләрне (зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар) аермачык әйтүдә күнектерергә.<br>2. Хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен имитацияләүне үстерергә.<br>3. Зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Ә.Ерикәйнең “Беренче кар” шигырен уку.<br>(Матур әдәбият). | 1. Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтергә дәвам итәргә; әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итәргә, кышкы күренешләр турында белемнәрен формалаштырырга; “йомшак”, “ап-ак” сыйфатлары хисабына сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>2. Катлаулырак сорауларга җавап бирә белүләрен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерергә.<br>3. Табигатькә мәхәббәт, туган телне өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Ләйлә суыктан курыкмый.<br>(О.И.Соловьева картинасы буенча).<br>(Танып белү) | 1. Картинада ясалган предметларны дөрес танып һәм атап, картинаны карарга өйрәтергә; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштырырга, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүдә күнектерергә.<br>2. Кабул итүне, игътибарны, хәтерне үстерергә.<br>3. Сюжетлы картинкалар карау теләге тәрбияләргә. |
| **IV – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Җ.Тәрҗемановның “Йокы бабай” әкиятен сөйләү.<br>(Матур әдәбият) | 1. Хикәянең эчтәлеген балаларга аңларга ярдәм итәргә.<br>2 Игътибар белән тыңлауларын үстерергә.<br>3. Бирелгән сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләргә. |
| **V – атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Күгәрченнәр, чыпчыклар – безнең нәни кошчыклар.<br>(Танып белү) | 1. Табигать объектларына булган кызыксынуларын стимуллаштырырга; мәйданчыкка килгән кошлар белән таныштырырга; “гөр-гөр”, “чырык-чырык”, “кар-кар” аваз ияртемнәрен ачык әйтүдә күнектерергә; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баетырга.<br>2. Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>3. Кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү, аларны тукландыру теләге тәрбияләргә. |
| **V – атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Тылсымлы таякчык.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтергә, аларның төсләр турындагы күзаллауларын ныгытырга. Төсне белдерә торган сыйфатларны активлаштырырга.<br>2. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, ишетү осталыкларын үстерергә.<br>3. Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |

| | | |
|---|---|---|
| **V – атна** **3-эшчәнлек** | С. Летованың “Кар бабай” хикәясен уку. (Матур әдәбият). | 1. Күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелектән башка гына тыңларга һәм сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итәргә, сүзлек запасын киңәйтергә (яхшы күңел, йомшак күңел, киң күңел).<br>2. Балаларның игътибарын, бергәләп тыңлау күнекмәсе үстерергә. |

## Февраль

| Сроклар | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|
| **I– атна** **1-эшчәнлек** | Безнең этиләр. (Сюжетлы картинкалар карау). (танып белү) | 1.Балаларны этиләр һөнәренә кагылышлы булган сюжетлы кечкенә картинкаларны карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтергә; эш гамәлләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>2.Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын.<br>3.Төрле профессия кешеләренә һәм этиләр хезмәтенә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **I– атна** **2-эшчәнлек** | “Шундый ук предметны тап” дидактик уены (сөйләм телен үстерү) | 1.Үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган фразалар (гади җөмләләр) белән белдерергә өйрәтергә. Гомумиләштерә белүдә күнектерергә. Аталган предметларны чынбарлыкта һәм картинада танырга өйрәтергә, предметларның билгеләнешен ачыкларга. Предметларның исемнәрен атау хисабына (сабын теш щеткасы, теш пастасы, сөлге, кыстыргыч) һәм сөйләмдә кулланылган фигыльләр ярдәмендә сүзлекне баетырга, активлаштырырга.<br>2.Тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгын, игътибарны, сенсор сәләтләрне үстерергә. |
| **I– атна** **3-эшчәнлек** | Ш.Маннурның “Яратам” шигырен уку. (матур әдәбият) | 1.Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; шигырьне тыңлау теләге уятырга, сорауларга аңлап җавап бирүдә, [ә] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>2.Балаларның игътибарын, кабул итүен үстерергә.<br>3.Әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләргә. |
| **II– атна** **1-эшчәнлек** | Безнең апа. (Тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү). (танып белү) | 1.Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш хәрәкәтләрен таный һәм атый белергә өйрәтергә (савыт-саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.); сүзлекне активлаштырырга, аны яңа сүзләр белән баетырга. Уенчыкларны зурлыгы буенча классификацияләргә өйрәтергә.<br>2.Балаларның игътибарын, күзәтәчәнлекне, тәрбиячене ишетә һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үти белү осталыгын үстерергә<br>3.Әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләргә. |
| **II– атна** **2-эшчәнлек** | Машина һәм самолет (Уенчыклар карау). (сөйләм телен үстерү) | 1.Балаларны уенчыкларның өлешләрен, сыйфат билгеләрен - төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтергә. Исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итәргә. [У] сузык авазын әйтүдә күнектерергә. Очучы, очып китү, очып төшү, йөк машинасы, самолет сүзләре хисабына сүзлекне активлаштырырга. Уенчыклар (машина, самолет) белән таныштыруны дәвам итәргә.<br>2.Балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерергә.<br>3.Шофер, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләргә. |
| **II– атна** **3-эшчәнлек** | “Кәккүк-чыпчык” уены. (матур әдәбият) | 1.[Ч] һәм [к] авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>2.Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>3.Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләүне дәвам иттерергә. |
| **III– атна** **1-эшчәнлек** | “Алсу бәйрәмгә җыена” дидактик уены. (танып белү) | 1.Якын тирәлектәге предметлар (киемнәр, аларның төсе һәм материалы) белән таныштыруны дәвам итәргә.<br>2.Балаларның игътибарын, хәтерен, сорауларны ишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>3.Курчак белән уйнарга теләк һәм курчакларга сакчыл караш тәрбияләргә. |

| | | |
|---|---|---|
| **II– атна** **1-эшчәнлек** | Тере һәм уенчык кошларны карау (танып белү) | 1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчык кош – дымка уенчыгы белән таныштыру, уенчык кошның нинди материалдан ясалган булуын ачыклау; төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәнүне дәвам итү;<br>3) кошлар белән кызыксыну, аларга карата сак караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **II– атна** **2-эшчәнлек** | «Теремкәй» рус халык әкиятен сөйләү (сөйләм телен үстерү) | 1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;<br>2) *Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Сорыколак, аю- Камытаяк* сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген баету, активлаштыру; игътибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү;<br>3) халык иҗатына кызыксыну  тәрбияләү. |
| **II– атна** **3-эшчәнлек** | «Чәбәк-чәбәкәбкәсе...» юаткычын уку (матур әдәбият) | 1)балаларныңюаткычны күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белүләренә ирешү; истә калдыру максатыннан, юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан берничә тапкыр кабатларга мөмкинлек бирү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын; кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) татар халык аваз иҗаты белән кызыксыну  тәрбияләү. |
| **III– атна** **1-эшчәнлек** | Шәхси гигена әйберләре белән таныштыру. (танып белү) | 1.Юыну әйберләре белән танышу, сабын, су, сөлге сүзләрен өйрәнеп, балаларның сүзлек байлыгын арттыру.<br>2.Тиз истә калдырырга өйрәтү.<br>3.Курчак үрнәгендә үз-үзеңне чиста тоту теләге тәрбияләү. |
| **III– атна** **2-эшчәнлек** | «Төлке, Куян һәм Әтәч» әкиятен сөйләү (сөйләм телен үстерү) | 1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү; сюжетның үсеше артыннан күзәтергә, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлек, кайгыртучанлык, ярдәмчеллек, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык хисләре тәрбияләү. |
| **III– атна** **3-эшчәнлек** | З. Туфайловның «Әни сүзе» шигырен ятлау. (матур әдәбият) | 1) балаларны шигырь белән таныштыру; истә калдыру максатыннан, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирүләренә ирешү;<br>2) балаларның аңга алуларын, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү, аларда уңай эмоцияләр тудыру;<br>3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү |
| **IV– атна** **1-эшчәнлек** | Табибка барабыз Тирә – юнь белән таныштыру | 1Балаларның табиб һөнәре турында гы белемнәрен ныгыту.<br>2.Логик фикер йөртү сәләтен үстерү.<br>3. Шәфкатьлелек, кызгану хисе уяту. |
| **IV– атна** **2 эшчәнлек** | Л. Толстойның «Өч аю» әкиятен уку (сөйләм  телен үстерү) | 1) балалар өчен зур күләмле булган әкиятне игътибар белән тыңлауларына һәм аңлауларына ирешү; сәнгатьле сөйләм ашабалаларда әдәби персонажларның эшгамәлләренә бәя бирү, үз кичерешләрен чагылдыра белү күнекмәләре формалаштыра башлау; сүзлекне активлаштыру, балаларның сәнгатьле сөйләмен үстерү;<br>2) балаларның аңга алуларын, игътибарын, фикерләүләрен үстерү;<br>3) әкиятләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| **IV– атна**<br><br>**3 эшчәнлек** | Г. Нәбиуллинаның «Әнигә булышам» шигырен уку.<br>(матур әдәбият) | 1) балаларны Г.Нәбиуллинаның шигыре белән таныштыру, бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү;<br>2) аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, диалогик сөйләмнәрен, кулларының вак моторикасын үстерү;<br>3) әниләргә ярдәм итү теләге, тырышлык, пөхтәлек тәрбияләү. |

## Апрель

| **Сроклар** | **Тема** | **Бурычлар** |
|---|---|---|
| **I– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Урамда яз”<br>(танып белү) | 1. балаларны язгы күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) ачыклау барышында сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2. балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү;<br>3. язгы күренешләр белән кызыксынуларын үстерү, табигатьтә барган үзгәрешләрне күрергә өйрәтү, шатлык хисләре уяту. |
| **I– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Бозау, колын бәрән турында сөйлибез”<br><br>(сөйләм телен үстерү) | 1. язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләрне турында күзаллауларын киңәйтү; тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә мәгънәдәге сүзләрне *(зур – кечкенә, калын – нечкә)* таба һәм куллана белергә өйрәтүне дәвам итү; балаларның аваз ияртәмнәрен әйтә белүләрен ныгыту;<br>2. балаларның аңга алуларын, монологик сөйләмен үстерү;<br>3. балаларда хайваннар тормышы белән кызыксыну тәрбияләү. |
| **I– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Д. Гарифуллинның “Тавыклар һәм Таһир” шигырен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. шигъри әсәр белән таныштыру; йорт кошлары турындагы белемнәрен тирәнәйтү; сорауларга аңлап, дөрес җавап бирүләренә ирешү; аваз ияртәмнәре әйтелешен ныгыту; бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту;<br>2. балаларның аңга алуларын, күзаллауларын, игътибарын, кул хәрәкәтләрен, иҗади сәләтләрен үстерү; фантазияләрен баету;<br>3. балаларда йорт кошларына карата кайгыртучанлык, үзләре башкарган эшкә шатлана белү хисләре тәрбияләү. |
| **II– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Йомшаккай бездә кунакта.<br>(Танып белү) | 1. Балаларның группадагы уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгы формалаштырырга, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлек запасын киңәйтергә.<br>2. Тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләге үстерергә.<br>3. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Яз, яз килә...”<br>(танып белү) | 1 . Балаларга язгы күренешләр турындагы элементар белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирергә. Сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга;<br>2. балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерергә;<br>3. язгы күренешләргә кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләргә шатлана белүләрен тәрбияләргә. |
| **II– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Р. Батулланың “Елак әтәч” әсәрен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. әкиятнең эчтәлеген аңлауларына, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүләренә ирешү; төрле орлыкларына (бодай, дөге) аера белергә өйрәтү;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарын, кул чукларының вак мускулларын үстерү; яңа сүзләрне сөйләмдә активлаштыру;<br>3. тешләрне саклау,алар турында кайгырту кирәклеген аңлауларына ирешү; кулҗтура – гигиена кагыйдәләре формалаштыру |

| | | |
|---|---|---|
| **III– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | Йомшаккай тагын бездә кунакта.<br>(Танып белү) | 1. Балаларны уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтергә; уенчыкларның өлешләре исемнәрен, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертергә.<br>2. Тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>3. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, көлкеле уенчыклар белән уйнаудан канәгатьләнү, шатлану хисләре тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Предметларның төсләрен тану һәм атау.<br>“Паровоз” дидактик күнегүе.<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баетырга (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтүдә күнектерергә.<br>2. Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерергә.<br>3.Эшчәнлеккә карата кызыксыну, бер-берең белән шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Б. Рәхмәтнең “Яз” шигырен ятлау<br><br>(матур әдәбият) | 1. балаларны Б. Рәхмәтнең “Яз” шигыре белән укып таныштыру, истә калдырырга ярдәм итү; эчтәлегенә туры китереп, сорауларга җавап бирергә өйрәтү, яз турында белемнәрен баету;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарларын, хәтерен, сөйләмнәренең сәнгатьлелеген үстерү;<br>3. шигырьдә сурәтләнгән язгы табигатькә карата кызыксыну, соклану хисе тәрбияләү. |
| **IV– атна**<br><br>**1-2 эшчәнлек** | Юыну бүлмәсен карау.<br>(Танып белү) | 1. Балаларның юыну бүлмәсендәге предметларның (сабын, сөлге, кран, су, теш щеткасы, теш пастасы) функциональ билгеләнеше турындагы күзаллауларын ачыкларга.<br>2. Сүзләрне (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.)төрле грамматик формаларда куллану осталыгын, сөйләм активлыгын, инициативасын үстерергә.<br>3. Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте**,** пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| **IV– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Х. Вахитның “Уңган сыерчык” шигырен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларына шигырь сүзләре белән җавап бирүләрен ныгыту; музыка астында түгәрәктә бер-берсенә комачауламый йөри белүләренә формалаштыру; кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарларын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3. балаларда туган якта мәххәбәт, җылы яктан кошларга карата кызыксыну, мәрхәмәтлек хисе тәрбияләү. |

## Май

| **Сроклар** | **Тема** | **Бурычлар** |
|---|---|---|
| **I– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” рәсемен карау<br>(Танып белү) | 1. балаларны тәрбияче ярдәме белән рәсемнең эчтәлеген аңларга, аның турында сөйләргә өйрәтү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2. балаларны аңга алуларын, игътибарын, диалогик сөйләмен, дуслык турында күзаллауларын үстерү;<br>3. тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белергә өйрәтү;хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **I– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Автобуста сәяхәт”<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ирешү, йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту, йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2. кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелә торган сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру; балаларның игътибарын, хәтерен, аңга алуларын үстерү;<br>3. тере һәм тере булмаган табигать белән кызыксыну тәрбияләү. |

| | | |
|---|---|---|
| **I– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | “Тилгән” эндәшен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. балаларның шигъри әсәрне тыңлый һәм аңлый белүләренә ирешү; шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзлекләрен баету, шигырь сүзләрен истә калдыруларына ирешү; кошлар (тилгән) турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарларын, конкрет-образлы фикерләвен үстерү;<br>3. балаларның шигырьне дөрес интонация белән сөйләүләренә ирешү. |
| **II– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Тузганак чәчәген карау”<br>(Танып белү) | 1. балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) таныштыруны дәвам итү;<br>2. үсемлекләрне карау барышында әңгәмә тарту;хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3. үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләре тәрбияләү. |
| **II– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Мин җәйне яратам”<br><br>(Сөйләм үстерү) | 1. табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләре сөйләмдә куллауларын активлаштыру, “бер”, “күп” төшенчәләрен ныгыту;<br>2. балаларның игътибарын, диалогик сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, аңга алуларын үстерү;<br>3. табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |
| **II– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | “Аю белән хатын” әкиятен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү; сүзлекне баету, сөйләмдә активлаштыру. [З] авызын дөрес, ачык әйтергә өйрәтү;<br>2. балаларның игътибарын, аңга алуларын, фикерләүләрен үстерү; чикләнгән пространствода йөгерергә өйрәтүне дәвам итү;<br>3. халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлек, кеше хәленә керә белүчәнлек хисләре тәрбияләү. |
| **III– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Йорт хайваннары”<br>(танып белү) | 1. Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтергә. Хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен атауда күнектерергә;<br>2. сүзлекне баетырга, тәрбиячнең сорауларына җавап бирү, активлык күрсәтү теләге үстерергә;<br>3. йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | Кем нәрсә эшли?<br>(Сөйләм үстерү) | 1. Балаларның, аралашу чарасы буларак, сөйләмен үстерергә ярдәм итәргә, картинкалар карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтергә.<br>2. Игътибарын, кабул итүләрен үстерергә.<br>3. Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| **III– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | Җ. Тәрҗемановаың “Кикрикүк” шигырен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлауларына ирешү; тема буенча сүзлекләрен баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатларга һәм аваз ияртәмнәрен дөрес әйтергә өйрәтү;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарларын, диалогик сөйләмнәрен, бармак хәрәкәтләрен үстерү; вакыт буенча (иртә-кич) ориентлашырга өйрәтә башлау;<br>3. балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү. |
| **IV– атна**<br><br>**1-эшчәнлек** | “Песиле тал бөреләрен карау”<br>(танып белү) | 1. Балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштырырга; табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итәргә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм сүзлекне активлаштырырга (песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле);<br>2. балаларның кабул итүен, игътибарын күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә;<br>3. табигать объектына карата сак караш, кызыксыну, табигатьтәге матурлыкны күрә белүләрен тәрбияләргә |
| **IV– атна**<br><br>**2-эшчәнлек** | “Балалар бакчасы ишегалдында”<br>(сөйләм телен үстерү) | 1. Исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштырырга. Фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерергә. Балаларны участокта үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итәргә. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрне киңәйтергә;<br>2. төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерергә; |
| **IV– атна**<br><br>**3-эшчәнлек** | М. Мазуновның “Кәҗә” шигырен уку<br><br>(матур әдәбият) | 1. шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирергә, аваз ияртемен дөрес өйрәтү;<br>2. балаларның аңга алуларын, игътибарларын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кулхәрәкәтләрен үстерү;<br>3. йорт хайваннары белән кызыксыну, алар турында кайгыртучанлык тәрбияләү. |

## Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы.

### Аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү Стратегиясе (30.12.2010, № 1174) – “Киләчәк” программасында мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учрежденияләре өчен Федераль дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирә алырдай укыту-методик комплектлар (УМК) булдыру бурычы куелган. Балалар бакчаларында балаларны татар теленә өйрәтү, аларның сөйләм телен үстерү өчен заман таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән эзлекле, максатчан методик әсбаплар белән тәэмин итү зарур. Әлеге максаттан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карары белән яңа укыту-методик әсбаплар төзелде.

Татар телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык аралашу даирәсе булдыру, сюжетлы уеннар оештыру, гомумән, баланың актив сөйләмен үстерү зарур. Сөйләшергә өйрәтү өчен баланы мөмкин кадәр күбрәк аралашуга җәлеп итәргә кирәк. Мәктәпкәчә тәрбия учрежденияләренең гомуми белем бирү программасы төзелешенә яңа федераль таләпләр буенча татар теле эшчәнлегенә бирелгән сәгатьләр санын бүлгәндә сөйләм телен үстерүгә күбрәк игътибар итү сорала.

Балалар бакчаларында заманча методик алымнар һәм чаралар куллану, татарча мультфильмнарны, электрон ярдәмлекләрне, аудио һәм видеоматерилларны урынлы файдалану аеруча мөһим.

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. 2010- 2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясендә балалар бакчаларында балаларга татар телен өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлешен тормышка ашыру максаты куелган.Мәктәпкәчә учрежденияләр,мәгариф системасының беренче баскычы буларак,нәниләрне татар теленә өйрәтүдә башлангыч роль уйный.

“Татарча сөйләшәбез” дип аталган методик комплект балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләргә кулланма буларак тәкъдим ителә. Комплектка, балаларның яшь үзенчәлекләренә карап, методик кулланма,күрсәтмә һәм таратма әсбаплар, аудио- һәм видеоматериаллар, балалар өчен эш дәфтәрләре туплап бирелде. Методик комплектлар өч яшь төркеме (уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәре) өчен әзерләнде, һәм аларның барысы да “Татарча сөйләшәбез” дип исемләнә. Бүгенге социолингвистик ситуациядә һәм гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары тормышка ашу кысаларында рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәтү буенча яңа укыту-методик кулланмалар эшләү зарурлыгы килеп басты. Билгеле булганча, телгә өйрәтүнең максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле, ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле өйрәтү максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

Балаларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, балалар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Баланың сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы** күздә тотыла:

- өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча тәрбияченең сорауларына жавап һәм сораулар куя белү;
- бирелгән үрнәк диалоглар буенча охшаш диалоглар төзү, әңгәмәдә катнаша алу;
- терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү.

**Телне аралашу аша өйрәнү принцибы.**

Атаклы психологлар А.Н.Леонтьев, П.Я.Гальперин хезмәтләре күрсәтүенчә, белемнәрне үзләштерү аларны нинди дә булса эшчәнлектә куллану аша бара. Башта белемнәр суммасы булдырып, аннан соң аны практикада кулланырга мөмкин дип уйлау хәзерге дидактик таләпләргә җавап бирми.

Сөйләмгә өйрәтү процессы башта аерым сүзләр, грамматик категорияләр өйрәнеп, аннан шулар нигезендә сөйләм оештыру аша барса, бу бик әйләнгеч, нәтиҗәсез юл булыр иде.

Коммуникатив технология нигезендә эчтәлек сайлау стратегиясе һәм тактикасы түбәндәгедән гыйбарәт була: башта балаларның яшь үзенчәлегенә карап, аларның аралашу сфералары, ситуацияләре ачыклана, аннан соң ул сфераларда сөйләшүне оештыра алырлык лингвистик материал сайлана. Бу процесс түбәндәге схемада күрсәтелә.

**Лингвистик материал сайлау схемасы**
**Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау**
**Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү**
**Сөйләм бурычларын ачыклау**
**Тиешле лингвистик материалны сайлау.**

Әлбәттә, эчтәлек сайлаганда сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен балаларның психо-физиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур. Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал балалар бакчасында телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

**Телне өйрәнү процессын индивидуальләштерү принцибы.**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын ойрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик – грамматик материалны балаларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә. Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр шөгыльгә программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Шөгыльләрдә ситуатив күнегүләрнең рус һәм татар телендә бирелүе балаларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора. Комплектларның төп максаты балаларны аралашуга өйрәтү.

**Укыту методик кулланма (УМК) өч проекттан тора һәр проект өчен:**

1) тематик план;
2) календарь – көндәлек план;
3) балалар өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоматериаллар;
5) мультипликацион сюжетлар;
6) күрсәтмә, таратма материаллар исемлеге;
7) диагностика төзелгән.

**Беренче проект “Минем өем”**

4-5 яшьлек балалар (уртанчылар төркеме) өчен.

**Икенче проект “Уйный – уйный үсәбез”.**

5-6 яшьлек балалар (зурлар төркеме) өчен.

**Өченче проект “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”**

6-7 яшьлек балалар ( мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен.

Һәр проектка 60 ар балалар эшчәнлеге (шөгыльләр) (детские виды деятельности) төзелгән, максат, бурычлар куелган:

**“Минем өем” проекты.**

**Максат:** Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты.**

**Максат:** Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

Бурычлар: 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.**

**Максат:** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:** 1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**“Минем өем” проекты:**

1) Аудиоматериал – 64 кисәк (ТРЭК),
2) Мультипликацион сюжет – 11 данә,
3) Эш дәфтәре – 17 бирем,
4) Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде),
5) Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 62 (269).

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты:**

1)Аудиоматериал – 63 кисәк (ТРЭК),
2)Мультипликацион сюжет – 15 данә,
3)Эш дәфтәре – 19 бирем,
4)Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде),
5)Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 46 (406).

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты:**

1)Аудиоматериал – 71 кисәк (ТРЭК),
2)Мультипликацион сюжет – 19 данә,
3)Эш дәфтәре – 20 бирем,
4)Күрсәтмәлелек (исемлеге бирелде)
5)Актив сүзләр+ сөйләм үрнәге – 60(483 сүз булган).

| №П/П | ЯШЬ АРАЛЫГЫ | АКТИВ (пассив) СҮЗЛӘР | СҮЗЛӘР САНЫ |
|---|---|---|---|
| 1. | 4-5 яшь | **Актив сүзләр:** эти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз) | **62 сүз** |
| 2. | 5-6 яшь | **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз) | **45 сүз** |
| 3. | 6-7 яшь | **Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный,<br>уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр (58 сүз)<br>**Пассив сүзләр:** нәрсә яратасың? (2 сүз) | **60 сүз** |

**Тәрбиячеләр өчен язылган методик кулланмада:**

1) Тематик план,
2) Шөгыльләр конспекты,
3) Диагностика .

**Бу укыту методик кулланмалар нәрсә белән аерыла соң?**

Бүгенге көндә балаларны татар теленә өйрәткәндә кулланыр өчен эш дәфтәрләре, аудиоматериаллар, мультипликацион сюжетлар булмады. Өч төркем өчен дә эш дәфтәрләре ясалган. Аларның эчтәлеген, биремнәрен, нинди рәсемнәр куллануны уйлап. Аудиоматериал, мультипликацион сюжетларның эчтәлеген шөгыльләргә туры китереп эшләнгән.

Эш дәфтәрләре, аудиоматериал һәм мультипликацион сюжетлар һәр шөгыльдә дә кулланылмый. Кулланылган очракта шөгыльнең бер өлеше булып бара.

**Мультипликацион сюжетлар** өченче шөгыльдә карау өчен уйлап эшләнелгән. Эчтәлеге 3-7 минут. Алар балаларның белгән сүз байлыгын, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Берничә шөгыль узгач өйрәнгән сүзләр һәм алдагы шөгыльләрдә сөйләмдә куллануга кертелә торган яңа сүзтезмәләр дә кулланыла.Бу мультипликацион сюжетларны караганнан соң балалар белән сорау – җавап тибында әңгәмәләр үткәрелә, вакыт калса алда өйрәнелгән уеннарны кабатларга тәкъдим ителә.

**Аудиоматериаллар:** танышу, яңа сүз, өйрәткәндә, диалог, сөйләм үрнәкләре, уеннар, кыска җырлар, өстәл театры күрсәткәндә куллану өчен төзелгән.

**Эш дәфтәрләре** шөгыльдә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелгән. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Бик уңай ягы, балалар үзләренең шөгыльдә эшләгән дәфтәрләрен өйгә алып кайтып кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән әти-әниләр дә, төркемдә эшләгән тәрбиячеләр дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылган.

Педагогикага багышланган әдәбиятне карап чыкканнан соң, нинди дә булса бер чараны гына алып, менә монысы гына тел өйрәнү өчен иң куәтлесе, иң кирәклесе, дип берсен генә аерып әйтеп булмый. Һәрбер автор төрле чараны атый

Һәм шуңа да, укыту-методик комплектының, күргәнегезчә, юнәлешләре күптөрле. Алар балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп эшләнелгән. Һәрбер юнәлеш билгеле бер үзенең максатын чишә. Билгеләп үтелгәнчә, гамәли дәфтәрләр, яки эш дәфтәрләре – заманча төзелгән укыту-методик комплектының төп юнәлешләренең берсе булып тора.

Дәфтәрләр балаларның педагог тарафыннан оештырылган эшчәнлектә алган белемнәрен ныгыту максатында куллану өчен тәкъдим ителә.

**Эш дәфтәренең дидактик функцияләре:**

1) Компенсаторная (компенсатор) – яки бу балаларга сүз өйрәтү процессын җиңеләйтү, баланың һәм тәрбиячененең көчен һәм вакытын экономияләү дигән сүз. Ниндидер дәрәҗәдә сәламәтлекне саклау аспектына да кагылып кителә. Тәрбияче белән балалар күмәк эшли, ә балалар исә эшчәнлек төрен үзгәртәләр.

2) Информативная (информатив) – яки балалар өчен иң кирәкле информацияне җиткерү;

3) Интегративная (интегратив) – өйрәнү объектын өлешләп һәм бербөтен итеп карау;

4) Познавательная (танып-белү) – баланың танып-белүен үстерү, яки күзәтүчәнлек, уйлау, эстетик матурлыкны күрә белүе;

5) Формирующая (формалаштыру)- баланың материалны үзләштерүе, танып –белү алымнары формалашуы.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән.

Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм). Шулай ук балалар күп кенә сораулар куярга өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар.

Нинди дә булса күзаллау булсын өчен, эш дәфтәрләрен интерактив тактага ясалган. Интерактив такта булган бакчалар өчен бу биремнәрне тактага күчерергә тәкъдим ителә, чөнки бу очракта, дәфтәрләрне балаларның үзләренә бирергә мөмкинлек туа, алар өйләрендә әти-әниләре белән бергәләп эшли алалар.

## “Минем өем” проекты буенча комплекслы – тематик план

## (уртанчылар төркеме)

# Сентябрь

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Танышу | **Сентябрь I-атна 1 эшчәнлек** | Татарча сөйләшергә теләк уяту, кызыксындыру. |
| Танышу | **Сентябрь I-атна 2 эшчәнлек** | Татар теленә кызыксыну уяту. |
| Әкият илендә | **Сентябрь I-атна 3 эшчәнлек** | Татар теленә кызыксыну уяту, мавыктыру. |
| Минем гаиләм | **Сентябрь II-атна 1-эшчәнлек** | 1. Яңа сүзләр һәм сөйләм үрнәге белән таныштыру.<br>2.Яңа сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>3.Татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту. |
| Минем гаиләм | **Сентябрь II-атна 2-эшчәнлек** | 1. Яңа сүзләр һәм сөйләм үрнәге белән таныштыру.<br>2.Яңа сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>3.Татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту. |
| Минем туганнарым | **Сентябрь II-атна 3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне ныгы-ту. Игътибарлылыкны үстерү. |
| Малай, кыз | **Сентябрь III – атна 1-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү. Татар теленә кызыксыну уяту. |
| Малай, кыз | **Сентябрь III – атна 2-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү. Татар теленә кызыксыну уяту. |
| Минем туганнарым | **Сентябрь III – атна 3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне ныгыту.<br>Татарча сөйләшергә теләк уяту. |
| Минем туганнарым | **Сентябрь IV – атна 1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне ныгыту.<br>Татарча сөйләшергә теләк уяту. |
| Малай, кыз | **Сентябрь IV – атна 2-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру дәвам итү.<br>Хәтер сәләтен үстерү. Татар теленә кызыксыну уяту. |
| Әкият илендә | **Сентябрь IV – атна 3-эшчәнлек** | Татар теленә кызыксыну уяту, мавыктыру. |

# Октябрь

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Әйдәгез, танышыйк | **Октябрь<br>I – атна<br>1 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **Мин, сау булыгыз, исәнмесез.**<br>Хәтер сәләтен үстерү. Татарча сөйләшергә теләк уяту. |
| Әйдәгез, танышыйк | **Октябрь<br>I – атна<br>2 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **Исәнме.**<br>Син кем? соравына аңлап җавап бирә белүләренә ирешү.<br>Бер-береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү. |
| Тату гаилә | **Октябрь<br>I – атна<br>3 - эшчәнлек** | Балаларның исәнләшә, саубуллаша белүләренә ирешү.<br>Зиһен сәләтен үстерү. |
| Әйдәгез, танышыйк | **Октябрь<br>II – атна<br>1 - эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне ныгыту, хәтер сәләтен үстерү.<br>Гади диалогта катнаша белүләренә ирешү.<br>Сөйләшергә теләк уяту. |
| Әйдәгез, танышыйк | **Октябрь<br>II – атна<br>2 - эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. Игътибарлылыкны үстерү. |
| Әйдәгез, танышыйк | **Октябрь<br>II – атна<br>3 - эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне ныгыту.<br>Сорауларга җавап бирә белүләренә ирешү. |
| Минем дуслар | **Октябрь<br>III – атна<br>1 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **Эт, песи.**<br>Син кем? соравына аңлап җавап бирә белүләренә ирешү. |
| Минем дуслар | **Октябрь<br>III – атна<br>2- эшчәнлек** | Син кем? Мин песи, мин эт, сүзтезмәләрен активлаштыру. |
| Әйдәгез дуслашыйк | **Октябрь<br>III – атна<br>3 - эшчәнлек** | Сюжетның эчтәлеген аңларга булышу. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |
| Әйе, юк | **Октябрь<br>IV – атна<br>1 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **Әйе, юк, сау бул.**<br>Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Әйе, юк | **Октябрь<br>IV – атна<br>2 - эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Качышлы уйныйбыз | **Октябрь<br>IV – атна<br>3 - эшчәнлек** | Сюжетның эчтәлеген аңларга булышу. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |

## Ноябрь

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Кунак килгән | **Ноябрь I – атна 1 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **Әби, бабай.** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Кунак килгән | **Ноябрь I – атна 2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Әйдәгез, уйныйбыз | **Ноябрь I – атна 3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Фикер сәләтен үстерү. |
| Безнең кунаклар | **Ноябрь II – атна 1-эшчәнлек** | 1. “Хәлләр ничек?” сөйләм үрнәген һәм “әйбәт” сүзен өйрәнү. 2. Сөйләм үрнәген сөйләмдә активлаштыру. 3. Татарча аралашуга теләк уяту. |
| Безнең кунаклар | **Ноябрь II – атна 2-эшчәнлек** | 1. Өйрәнгән сүзләр аша сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру. 2. Дәфтәрдәге биремнәр аша өйрәнгән материалны ныгыту. 3. Игътибарлылык тәрбияләү. |
| Шалкан әкияте | **Ноябрь II – атна 3-эшчәнлек** | Тапшыруның эчтәлеген аңларга булышу. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |
| Әби күчтәнәче | **Ноябрь III – атна 1 – эшчәнлек** | Яңа сүз белән таныштыру: **ипи.** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Бабай күчтәнәче | **Ноябрь III – атна 2 – эшчәнлек** | Яңа сүз белән таныштыру: **алма.** Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Безнең кунаклар | **Ноябрь III – атна 3 – эшчәнлек** | Тапшыруның эчтәлеген аңларга булышу. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |
| Сөт, чәй | **Ноябрь IV – атна 1 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **чәй, сөт.** Хәтер сәләтен үстерү. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |
| Дустыңны сыйла | **Ноябрь IV – атна 2 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру. Фикер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Безнең кунаклар | **Ноябрь IV – атна 3 эшчәнлек** | Тапшыруның эчтәлеген аңларга булышу. Татарча өйрәнергә теләк уяту. |

# Декабрь

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Рәхмәт әйт | **Декабрь**<br>**I – атна**<br>**1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Песине сыйла | **Декабрь**<br>**I – атна**<br>**2 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **тәмле, кил монда.**<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Рәхмәт әйт | **Декабрь**<br>**I – атна**<br>**3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Кунак сыйлау | **Декабрь**<br>**II– атна**<br>**1 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **утыр.**<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Тәмле кибетендә | **Декабрь**<br>**II– атна**<br>**2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Әкият илендә | **Декабрь**<br>**II– атна**<br>**3 эшчәнлек** | Татар теленә кызыксыну уяту, мавыктыру. |
| Кунакны ашат | **Декабрь**<br>**III – атна**<br>**1 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **аша.**<br>Гади диалогта катнаша белү.<br>Хәтер, зиһен үстерү. |
| Чәй табынында | **Декабрь**<br>**III – атна**<br>**2 - эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **эч.**<br>Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Әкият илендә | **Декабрь**<br>**III – атна**<br>**3 - эшчәнлек** | Татар теленә кызыксыну уяту, мавыктыру. |
| Азат кунак чакыра | **Декабрь**<br>**IV– атна**<br>**1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Дустыңны сыйла | **Декабрь**<br>**IV – атна**<br>**2 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Шалкан әкияте | **Декабрь**<br>**IV – атна**<br>**3 эшчәнлек** | Тапшыруның эчтәлеген аңларга булышу.<br>Татарча өйрәнергә теләк уяту. |

## Гыйнвар

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Уенчыклар | **Гыйнвар<br>II– атна<br>1-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **бир, туп.**<br>Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Зур – кечкенә | **Гыйнвар<br>II– атна<br>2-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **зур, кечкенә.**<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Күңел ачу кичәсе -“Туган көн”. | **Гыйнвар<br>II– атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Курчак кунакка килгән | **Гыйнвар<br>III– атна<br>1-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру: **матур, курчак.**<br>Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уенчыклар кибете | **Гыйнвар<br>III– атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Әкият илендә | **Гыйнвар<br>III– атна<br>3-эшчәнлек** | 1.Тапшыру барышында өйрәнгән сүзләрне хәтердә ныгыту.<br>2.Татар телен өйрәнүгә теләк уяту. |
| Уенчыклар кибете | **Гыйнвар<br>IV– атна<br>1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Тәмле кибетендә | **Гыйнвар<br>IV– атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Паркка сәяхәт | **Гыйнвар<br>IV– атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

## Февраль

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Курчак кунакка килгән | **Февраль<br>I – атна<br>1-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру. Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уенчыклар кибете | **Февраль<br>I – атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Паркка сәяхәт | **Февраль<br>I – атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| Яңа уенчыклар | **Февраль**<br>**II – атна**<br>**1-эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру. Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Уйныйбыз | **Февраль**<br>**II – атна**<br>**2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Без уйнарга яратабыз | **Февраль**<br>**II – атна**<br>**3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Мияуга бүләк | **Февраль**<br>**III– атна**<br>**1 -эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уенчыклар кибете | **Февраль**<br>**III– атна**<br>**2 -эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчыклар үпкәләгән | **Февраль**<br>**III– атна**<br>**3 -эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Яңа уенчыклар | **Февраль**<br>**IV– атна**<br>**1 -эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру. Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү.<br>Аралашу теләге тудыру. |
| Уйный<br>быз | **Февраль**<br>**IV– атна**<br>**2 -эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Алсу<br>ның туган көне | **Февраль**<br>**IV– атна**<br>**3 -эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

## Март

| Тема | Үткәрү вакыты | Бурычлар |
|---|---|---|
| Бүләкләр | **Март**<br>**I – атна**<br>**1-эшчәнлек** | Яңа сүз белән таныштыру. Хәтер сәләтен үстерү. Аралашу теләге тудыру. |
| Уйна | **Март**<br>**I – атна**<br>**2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Күңелле уеннар | **Март**<br>**I – атна**<br>**3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| Уенчыклар юабыз | **Март<br>II – атна<br>1-эшчәнлек** | Яңа сүз белән таныштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчык ю! | **Март<br>II – атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Акбай һәм Мияу маҗаралары | **Март<br>II – атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уенчыклар юабыз | **Март<br>III – атна<br>1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчык ю! | **Март<br>III – атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчыклар юабыз | **Март<br>III – атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Уенчыклар юабыз | **Март<br>IV – атна<br>1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчыклар юабыз | **Март<br>IV – атна<br>2-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| “Әкият илендә” | **Март<br>IV – атна<br>3-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

## Апрель

| **Тема** | **Үткәрү вакыты** | **Бурычлар** |
|---|---|---|
| Саннар | **Апрель<br>I атна<br>1 эшчәнлек** | Яңа сүзләр белән таныштыру.<br>Хәтер сәләтен үстерү. |
| Саннар | **Апрель<br>I атна<br>2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Уйныйбыз да, саныйбыз да | **Апрель<br>I атна<br>3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |

| | | |
|---|---|---|
| Уенчыклар | **Апрель<br>II атна<br>1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Ничә уенчык? | **Апрель<br>II атна<br>2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уйный-уйный санйыйбыз | **Апрель<br>II атна<br>3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Бергәләп -уйныйбыз | **Апрель<br>III атна<br>1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Фикер сәләтен үстерү. |
| Кунак чакырабыз | **Апрель<br>III атна<br>2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Күңелле ял итәбез | **Апрель<br>III атна<br>3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Без татарча сөйләшәбез | **Апрель<br>IV атна<br>1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Бер-берене тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү. |
| Бу өйдә кем яши? | **Апрель<br>IV атна<br>2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Без театр уйныйбыз | **Апрель<br>IV атна<br>3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Аралашу теләге тудыру. |

## Май

| **Тема** | **Үткәрү вакыты** | **Бурычлар** |
|---|---|---|
| Без татарча сөйләшәбез | **Май<br>I атна<br>1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Бер-берене тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү. |
| Акбай, Мияу кунак чакыра. | **Май<br>I атна<br>2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Без театр уйныйбыз | **Май<br>I атна<br>3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Аралашу теләге тудыру. |

| | | |
|---|---|---|
| Бергәләп -уйныйбыз | **Май**<br>**II атна**<br>**1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү.<br>Диалогта катнашу. |
| Кунак чакырабыз | **Май**<br>**II атна**<br>**1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Күңелле ял итәбез | **Май**<br>**II атна**<br>**3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| Уенчыклар | **Май**<br>**III атна**<br>**1 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. |
| Ничә уенчык? | **Май**<br>**III атна**<br>**2 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уйный-уйный саныйбыз | **Май**<br>**III атна**<br>**3 эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү. |
| Уенчыклар юабыз | **Май**<br>**IV – атна**<br>**1-эшчәнлек** | Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.<br>Фикер сәләтен үстерү. Әдәплелек кагыйдәләрен тәрбияләү. |
